# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ
# КАРАРЫ

**№ 2** **07 октябрь 2022 ел**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль
Районы Туйкә авыл җирлеге составына керүче
Туйкә авылында 2023 елда гражданнарның
үзара салымын кертү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлеге Туйкә авылында гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Туйкә авыл җирлеге Туйкә торак пункты территориясендә 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан, махсус хәрби операциядә катнашучы иректе көчләргә, контракт буенча хәрби хезмәткәрләрне Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылучылар тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 (Дүрт йөз) сум күләмендә, 2 группа инвалидлар, 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар, күп балалы гаиләләр өчен 200 (Ике йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләүне киметеп үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәгеләргә юнәлдерергә:

- Җирләү урыннарын карап тоту (дератизация, тоташ гербицид белән химик эшкәртү, агач кисү, куакларны кисү, үлән чабу, чүп-чар җыю, хуҗалык инвентаре, инструментлар һәм җиһазлар алу) Туйкә авылы;
- Туйкә авылында урам утларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (урам утлары, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү, килешү буенча эшләр өчен түләү).;
- Туйкәдә тракторчыга карны механикалаштырып җыю буенча хезмәтләр өчен түләү (чит оешмаларның юлларны кардан чистарту буенча хезмәтләре);;
- Туйкә авылы территориясендә үлән чабу (килешү буенча эш өчен түләү);
- халыкны су белән тәэмин итүне, ташландык суларны агызуны оештыру (су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау һәм карап тоту, материаллар, җиһазлар сатып алу, авария хәлләрен бетерү, торбаларны алыштыру, эчәргә яраклы суны биохимик һәм бактериологик анализлауны үткәрү, килешү буенча эшләр өчен түләү) Туйкә авылында;
- Туйкә авылында бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү (бүләк, сувенир продукция сатып алу, «Җиңү көне», «Сабантуй», «авыл бәйрәме», «Халыкара өлкәннәр көне», «Яңа ел» бәйрәм чараларын үткәрү буенча хезмәт күрсәтү);;

- Трактор өчен җиһазлар һәм запас частьләр сатып алу ( төягеч, чапкыч).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга:

ТР, Азнакай муниципаль районы, Түйкә авылы, Җәлил ур.,19 йорт;

ТР, Азнакай муниципаль районы, Түйкә авылы Гагарин ур., 4а йорт.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Туйкә авыл җирлеге Башлыгы — Закирова Р.Р.